Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

**Арча шәһәр Советы**

**карары**

**« 18 » апрель 2016 ел** **№ 32**

**Арча шәһәр Советының 05.11.2016 №20 карары белән расланган Арча шәһәр Советы һәм Арча шәһәре Башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Арча шәһәре Советы һәм Арча шәһәре Башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезлзмзгз үзгәрешләр кертү турында**

"Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 июлендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга яраштыру максатыннан Арча шәһәре Советы карар чыгарды:

1. Арча шәһәре Советы һәм Арча шәһәре Башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Арча шәһәре Советы һәм Арча шәһәре Башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә, Арча шәһәре Советы тарафыннан 2016 елның 05 ноябрендәге 20 номерлы карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләр кертегез:

1) 6 нчы пунктта киләсе редакциядә бәян итәргә:

в) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (катнашу өлеше, оешмаларның устав (туплау) капиталларында пайлар), аның хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ

булмаган балаларының календарь ел дәвамында кылган чыгымнары турында белешмә өчен; алдагы елда мәгълүматлар тапшыру (алга таба - отчет чоры) әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елда отчет чорына кадәр булган гомуми кеременнән һәм әлеге килешүләр хисабына ясалган акчаларны алу чыганаклары турында күбрәк булса.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев